СОВЕТ АКСУБАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10.12.2021 п.г.т. Аксубаево № 93

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының «Муниципаль милектә булган, аларда урнашкан биналар, төзелешләр, корылмалар милекчеләренә аерып бирелә торган җир кишәрлекләрен сату турында» 11.03.2016 ел, №32 карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.4 статьясына, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Җир кодексының 39.20 статьясында каралган очракларда, Татарстан Республикасы милкендәге яки аларга карата дәүләт милке чикләнмәгән, аларда урнашкан биналар, корылмалар, мондый биналар, төзелешләр яисә корылмалар милекчеләренә аерып бирелә торган җир кишәрлекләрен сату турында» 2012 елның 3 октябрендәге 827 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында»2021 елның 12 мартындагы 124 номерлы карарына, Аксубай муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының «Муниципаль милектә булган, аларда урнашкан биналар, төзелешләр, корылмалар милекчеләренә аерып бирелә торган җир кишәрлекләрен сату турында» 2016 елның 11 мартындагы 32 номерлы карарына, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Россия Федерациясе Җир кодексының 39.4 статьясына, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясына, Аксубай муниципаль районы Уставына таянып, ТР Аксубай муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.20 статьясында каралган очракларда, муниципаль милектә булган һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләренә карата торглар үткәрмичә генә сату-алу шартнамәсен төзегәндә, җир кишәрлегенең бәясе, әлеге карарның 2 пунктында билгеләнгән очраклардан тыш, мондый җир кишәрлегендә урнашкан биналар, төзелешләр яисә корылмалар милекчесе

мөрәҗәгать иткән вакытта гамәлдә булган җир кишәрлегенең кадастр бәясенең 100 проценты күләмендә билгеләнә.

2.Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2024 елның 1 гыйнварына кадәр муниципаль милектә булган яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләренә карата, аларда урнашкан биналар, төзелешләр, корылмалар милекчеләренә аерып бирелә торган җир кишәрлекләре кыйммәтен билгеләү өчен, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.20 статьясында (алга таба - җир кишәрлекләре) каралган очракларда, аларда урнашкан биналарның, төзелешләрнең яисә алардагы корылмаларның милекчеләренә сатканда, җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсен төзегән очракта, әлеге карар үз көченә кергәнче, җир бәясе тәшкил итә дип:

халык саны 500 мең кешедән артык булган Татарстан Республикасы торак пунктларында – җир кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен җир салымының 17 ставкасы күләмендә;

халык саны 500 мең кешегә кадәр булган Татарстан Республикасы торак пунктларында – җир кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен җир салымының 10 ставкасы күләмендә;

биналар, төзелешләр, корылмалар милекчеләре үзләрендә арендада булган торак пунктлар чикләреннән читтә -җир кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен җир салымы ставкасының өч тапкыр күләмендә;

2024 елның 1 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Җир кодексының 33.3 статьясы нигезендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен сатулар уздырмыйча гына әлеге карар үз көченә кергәнче бирелгән җир кишәрлекләре бәясе, инвестицион проектны тулы күләмдә гамәлгә ашыру шарты белән, әлеге пунктның өченче-бишенче абзацларында каралган күләмнәрдә билгеләнә;

биналар, тозелешләр, корылмалар милекчеләре үзләрендә арендада булган җир кишәрлекләрен җир кишәрлеге кадастр кыйммәтенең ике ярым процентка тигез булган бәядән түбәндәге очракларда сатып ала, әгәр булса:

«Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 137-ФЗ номерлы Федераль закон) үз көченә кергән көннән алып 2012 елның 1 июленә кадәр күрсәтелгән җир кишәрлекләренә карата даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукын яңадан рәсмиләштерү гамәлгә ашырылды;

әлеге җир кишәрлекләре 2012 елның 1 июленә кадәр 137-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән көннән алып аренда хокукына даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукын яңадан рәсмиләштерү гамәлгә ашырылган җир кишәрлекләреннән төзелгән.»

3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының http://aksubayevo.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http //pravo. tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Аксубай муниципаль районы Советының агросәнәгать комплексы, җирдән файдалану һәм экология мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы Башлыгы,
Совет рәисе К.К.Гыйлманов